**ГЛАВА БОЛЬШЕКАБАНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул.Южная, дом 1, село. Малые Кабаны
422623, телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ КАБАН ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**
Кәньяк урамы, 1 нчы йорт,
Кече Кабан авылы,
422623 телефон/факс(84378)4-22-02
E-mail: Bkab.La@tatar.ru

**2024 елның 10 июле** **6 номер**

# КАРАР

## Җир кишәрлеген шартлы рәвештә файдалануга рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясына, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы «Макаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясына нигезендә, территориянең тотрыклы үсешен, инженерлык транспорт һәм социаль инфраструктураларны үстерүне тәэмин итү, гражданнар һәм аларның берләшмәләре мәнфәгатьләрен исәпкә алуны тәэмин итү максатларында, Макаровка авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. ТР, Лаеш муниципаль районы, Олы Кабан авылы, Совет урамы, 10 ж/к, адресы буенча урнашкан 16:24:160101:3673 кадастр номерлы, җир кишәрлеген «гомуми файдалану территориясе» төреннән файдалануның шартлы рөхсәт ителгән «элемтә бүлеге» төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Олы Кабан авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш Кагыйдәләре проектын әзерләү комиссиясенә 2024 елның 30 июлендә 15.00 сәгатьтә ТР, Лаеш муниципаль районы, Олы Кабан авылы, Җиңү ур., 5 й.адресы буенча урнашкан Олы Кабан мәдәният йорты бинасында ачык тыңлаулар үткәрергә.

3. Ачык тыңлауларга чыгарыла торган мәсьәлә буенча тәкъдимнәрне һәм искәрмәләрне түбәндәге адрес буенча язма рәвештә 2024 елның 29 июленә кадәр түбәндәге адрес буенча җибәрергә: ТР Лаеш районы Кече Кабан авылы, Южная ур., 1 й..

4. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Макаровка авыл җирлегенең махсус мәгълүмати стендларында урнаштырырга(халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Башлык-Татарстан Республикасы
Лаеш муниципаль районы Макаровка
авыл җирлеге Советы рәисе И.Г. Шәрәфиев